Республика Татарстан
СОВЕТ СТАРОКАШИРСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
САРМАНОВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
ул. Комсомола, д. 4а,
с. Старый Кашир
423357
Телефон: 4-86-36

Татарстан Республикасы
САРМАН
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОН
ИСКЕ КӘШЕР АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
СОВЕТЫ

Иске Кәшер авылы, Комсомол урамы,
4а йорты, 423357
Телефон: 4-86-36

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

**№ 12** **21.06.2024**

Җирле салымнар суммалары өлешендә бурычн
ы түләтүгә ышанычсыз дип тануның өстәмә ниге
зләрен билгеләү турында.

«Төбәк салымнары суммалары өлешендә бурычларны түләтүгә ышанычсыз дип тануның өстәмә нигезләрен билгеләү турында» 2024 елның 12 апрелендәге 18-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Сарман муниципаль районының «Иске Кәшер авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, Сарман муниципаль районының Иске Кәшер авыл җирлеге Советы карар итте:

1. Җирле салымнар суммалары өлешендә бурычны түләтүгә ышанычсыз дип тануның өстәмә нигезләрен билгеләргә.

- варислар мирас хокукыннан баш тарткан, варислар булмаган яки мирас ачылганнан соң бер ел эчендә мирасны кабул итмәгән очракта үлгән яки үлгән дип игълан ителгән физик затларда бурычлар булу;
- Россия Федерациясе Салым кодексының 48 статьясында билгеләнгән сроклар тәмамланганнан соң физик затларда 500 сумнан артмаган суммада бурыч булу.
- Җирле салымнар суммалары буенча бурычларны түләтүгә ышанычсыз дип тануның өстәмә нигезләре булуын раслаучы документла түбәндәгеләр:

1) әлеге карарның 1 пунктының 1 пунктчасында күрсәтелгән нигез булганда:

а) физик затның яшәү урыны буенча салым органының бурыч суммасы турында белешмәсе;

б) үлем белән бәйле рәвештә салым органнарында физик затны исәптән төшерү турында мәгълүмат;

в) мирас хокукы турында таныклык бирү турында мәгълүмат булмау турында салым органы белешмәсе;

2) әлеге карарның 1 пунктындагы 2 пунктчасында күрсәтелгән нигез булганда, салым органының 500 сумнан артмаган бурыч булу турында белешмәсе.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә бастырып чыгарырга, шулай ук Сарман муниципаль районының рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Иске Кәшер авыл җирлегенең мәгълүмати стендларында урнаштырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстәмә алам.

Татарстан Республикас
Сарман муниципаль район
Иске Кәшер авыл җирлеге
Совет рәисе Р.Н.Дәүләтҗанов